| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВ ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

28.07.2023 Казан ш. № 2052-р

Бүлгеч газүткәргеченең саклык зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш муниципаль районнары территориясендәге газ бүлгеч челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен урнаштыру турында” 21.12.2017 № 3008-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУның (№ 04А-04/1434 от 14.06.2023) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. «Газпром трансгаз Казань» ЖЧЖ милкендә Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районы территориясендә булган, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш муниципаль районнары территориясендәге газ бүлгеч челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен урнаштыру турында” 21.12.2017 № 3008-р карары (алга таба - № 3008-р карары) нигезендә урнаштырылган 9900000561 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын 16:21:040604:6 кадастр номерлы җир кишәрлегендә күрсәтелгән газүткәргечнең 125,1 м.ына демонтаж ясалу һәм 164,6 м. монтаж ясау сәбәпле «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы (10738 ± 36) кв.м.лы территория рәвешендә 2553 м м.ны тәшкил итә.

2. Эксплуатацияләү срогында 9900000561 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлгеч челтәрләрне саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 3008-р карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга кирә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан 41,409 км озынлыктагы, территориясе 0,16163 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябеннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.»;

әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 9900000561 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечкә туры килгән юлны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**